**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында граждannar җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 5

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлар, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)торак пункт территориясен төзекләндерү (Сарабиккол авылының Корчагин урамындагы, Такташ урамындагы иске агачларны кисү; Сарабиккол авылының Такташ урамына балалар мәйданчыгын сатып алу һәм койма белән әйләндереп алу; Сарабиккол авылы территориясендә кулдан үлән чабу; МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы сатып алу, май, фильтр); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (коры-сары һәм чүп үләннәреннән территорияләрне чаптыру, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү, башка төр эшләр); асылмалы җайланмалар сатып алу: трактор өчен ковш (тешле);

2)Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Сарабиккол авылындагы "Күкерт чишмәсе» чишмәсен капиталь ремонтлау һәм аңа якын территорияне төзекләндерү; Сарабиккол авылында «Бабай чишмәсе"чишмәсен косметик ремонтлау;

3)торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сарабиккол авылының Киров, Такташ, Корчагин, Тукай урамнары буенча юлларга вак таш салу).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы, Пионер урамы, 45 йорт - "Сатурн-Урал" ҖЧҖ, Киров ур., 3А йорт - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Киров ур., 4А йорт - мәдәният йорты бинасы,

Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина